Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

# ТЫЛСЫМ+

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

№1 (55)

Октябрь, 2023 нче ел

Бу санда

*Әлкәннәр һәм укытучылар көне* 2

*Укытучы - изге һөнәр ияс*е 2

*Бүгенге дәрес иртәгә дә кирәк була* 3

*Ата һөнәре - балага мирас* 3

*Алдынгылар хәрәкәте* 4

*Психолог киңәшләре* 4

**Гимназия - социаль челтәр битләрендә**

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Без сезнең белән горурланабыз!!!



Мөслимебездә Республика көнендә “Хезмәткә – дан” скверындагы фоорәсемнәр яңартыла. Әлеге чара традициягә әйләнде һәм анда гимназия укучыларының фоторәсемнәрен ел саен диярлек күрергә була.

2023 елгы нәтиҗәләрдән чыгып биология һәм химия фәннәреннән 100әр балл җыйган Лиана Исмәгыйлова, химия укытучысы Венера Гайсә кызының фотолары "Хезмәткә - дан" скверында үз урыннарын алдылар.

### Ата-аналар университеты




Икенче октябрьдә район мәдәният йортында гимназиядә белем алучы укучыларның әти-әниләренә ата-аналар университеты уздырылды. Әлеге чарада Мөслим гимназиясе директоры Мирзаянов А.Ф., Мәгариф идарәсе начальнигы Хәбибуллина Л.Я., лаеклы ялдагы педагог-укытучы Низамиева Т.Г., социаль мәсьәләләр буенча район Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Бәдретдинова М.Р., Әһлиуллина Я.Ф., үзәк шифаханәнең балалар табибы чыгыш ясадылар.

Алар барысы да ата – аналарның балалар өчен ачык үрнәк булуын билгеләп үттеләр. Еш кына, киләчәк бүген төзелә, диләр. Ата-аналар аны төзүдә катнашып, тагын бик әһәмиятле бер эш башкара – яшь буынга тәрбия бирә, иртәгәсе көн төзүчеләрен әзерли. Әйе, иртәгәсе көн өчен барыннан да бигрәк ата-аналар җаваплы.

### *Сау бул җәй, исәнме көз!*



*Җәй...*

*һәр мәктәп укучысының да аеруча яраткан, көтеп алган ел фасылы – ул җәйдер. Ни өчен? Чөнки нәкъ менә җәй аена балаларның 90 көн ялы туры килә. Ә ялны кем яратмый? Әлбәттә һәркем ялны бик ярата. Иртән иртүк торып мәктәпкә барасы юк, дәрес хәзерлисе юк. Менә шундый матур, ямьле җәй айлары үтеп тә китте.*

*Бусагада алтын көз. Көзнең дә үзенә күрә аерым матурлыгы, сихрилеге, кайвакытта моңсулыгы була.*

*Күп укучылар яңа уку елын түземсезлек белән көтеп алгандыр дип ышанасы килә. Укулар тулы көченә башланды. Тиздән кабат көзге каникул җитә.*

*“Тылсым+” гимназия газетасы укытучылар, мөгаллим, остазларга җылы теләкләрен юллый: сезгә олы рәхмәтләребезне җиткерәбез, имин тормыш, нык сәламәтлек, гаилә бәхете һәм берсеннән-берсе тырыш, белемле, рәхмәтле укучылар телибез. Балалар күңеленә миһербанлык орлыклары чәчегез! Ул орлыклар, һичшиксез, шытып чыгар, чәчәк атар, сезне матур-матур җимешләре белән сөендерер...*

*Укучыларга да “Тылсым+” газетасының теләк-тәкъдимнәре бар: ялкауланмаска, актив булырга, һәрнәрсә белән кызыксынырга. Күпне белергә теләүчеләргә мөмкинлекләрнең чиге юк.*

***“Тылсым+” гимназия газетасы редколегиясе***

## ӨЛКӘННӘР ҺӘМ УКЫТУЧЫЛАР КӨНЕ




Өлкәннәр көне һәм укытучылар көне уңаеннан гимназиядә бик матур чара үтте. Иртән ук күңелләрдә бәйрәм рухы тантана итте. Укучылар елмаеп, котлау сүзләре белән укытучыларны, өлкәннәребезне каршы алдылар.

Лаеклы ялдагы укытучылар иртән сыйныф сәгатьләрендә катнашып, үзләренең мәктәпләрдә укыткан елларын сөйләделәр, укучыларга киңәшләрен бирделәр. Аннары актлар залында бик күңелле чара булып узды. Укучылар әлеге көнгә багышлап концерт программасы әзерләгәннәр иде.

Фойеда көн дәвамында фотозона эшләде.

## УКЫТУЧЫ - ИЗГЕ ҺӨНӘР ИЯСЕ

***7 нче в сыйныфы укучылары яза***



Минем яраткан укытучым – биология укытучысы Ләйсән Фәгыйм кызы.

Ул һәрвакыт елмая һәм безгә игелекле. Ләйсән Фәгыймовна – үз эшенең чын профессионалы. Ул материалны бик яхшы аңлата, һәм безнең сыйныфта һәрвакыт дуслык атмосферасы һөкем сөрә. Ләйсән Фәгыймовна дәресләрне һәр укучы өчен кызыклы, аңлаешлы итәргә тырыша. Ул һәрвакыт ярдәм итәргә, авыр темаларны кабат аңлатырга, сорауларга җавап бирергә әзер.

Аның ярдәмендә мин биология фәнен ярата башладым.

Ләйсән Фәгыймовна, хезмәтегез өчен рәхмәт сезгә!

***Замалова Зәринә***

***



Минем яраткан укытучым - сыйныф җитәкчесе Гөлшат Марс кызы. Зифа буйлы, матур гына ханым. Ул укытучы гына түгел, ул - остаз, һәрвакыт ярдәм итергә әзер. Гөлшат Марсовна бик кайгыртучан кеше, безнең проблемаларны игъбарсыз калдырмый, игътибар белән тыңлый һәм беренче карашка авыр булса да, чишелеш табырга тырыша.

Сыйныф җитәкчебез үз эшен чыннан да ярата һәм аңа зур җаваплылык белән карый. Ул укытучы гына түгел, безнең өчен дус та, сердәш тә. Һәр укучыга индивидуаль якын килә.

Сыйныфыбызда ышаныч һәм хөрмәт атмосферасын тудыра. Бу безгә бер-беребез белән иркен аралашырга, үз фикеребезне белдерергә мөмкинлек бирә.

Аның безнең сыйныф тормышында катнашуы аркасында без бик күп кызыклы чаралар үткәрәбез, алар безгә бер-беребезне яхшырак белергә һәм команда буларак берләшергә ярдәм итә.

Мин Гөлшат Марсовнага бик рәхмәтлемен. Аның тормыш дәресләре һәрвакыт кызыклы,үзе – барыбызга да үрнәк.

***Насирова Мәрьям***

***



Мин барлык укытучыларны да бертигез яратам, ләкин иң яраткан укытучым Авзалова Зилә Зәфәр кызы.

Аның дәресләре кызыклы, мавыктыргыч үтә. Зилә Зәфәровнаның ачык йөзен күргәч туган тел һәм әдәбияты дәресен өйрәну теләге туа. Ул һәр теманы йөрәге аша үткәреп аңлата.

***Дәүләтшина Адилә***

***"Яшь буынның киләчәге, аларның язмышы укытучы кулында, аның алтын йөрәгендә", - дигән бөек рус язучысы Александр Фадеев.***



Минем яраткан укытучым Чулпан Алмазовна. Ул рус теле һәм рус әдәбиятеннән белем бирә. Без сыйныфыбыз белән аның дәресләрен көтеп алабыз.

Укытучыбыз безгә темалар гына аңлатып калмый, ул шулай ук безнең иҗади сәләтләребезне дә үстерә.

Чулпан Алмазовна искиткеч кеше һәм бик яхшы дус. Аның дәресләрендә рус теленең бөеклеген тагын да аңлыйсың. Язучыларның әсәрләрен икенче яктан ачасың.

***Айгильдина Зарина***

## АТА ҺӨНӘРЕ - БАЛАГА МИРАС

### Әтиләр көне

***Әтиләр көнен бәйрәм итү кысаларында, безнең гимназиядә башлангыч сыйныфлар һәм урта звено укучылары һәм аларның әтиләре өчен квест-уен узды. Балалар һәм әтиләр командаларда ярышып үзләренең җитезлекләрен, тапкырлыкларын күрсәттеләр.***





### Әтием - горурлыгым!



Минем әти Сәетгалиев Илнар. Аңа 35 яшь. Әтием хәзерге вакытта “Агромастер” җитештерү компаниясендә баш инженер булып эшли.

Ул буш вакытларында балык тотарга ярата. Минем әти бәләкәйдән үк көрәш белән шөгыльләнә. Күп еллар Мөслим батыры исеменә лаек булды. Аның мактау кәгазьләренең һәм медальләренең иге-чиге юк. Ул Татарстан чемпионы, билбау көрәше буенча Россиядә икенче урын иясе.

Әтиемнең кулыннан килмәгән эше юк. Кирәк булса ашарга да пешерә, өйне дә җыештыра. Безне дә эш эшләргә өйрәтә. Мин әтиемне яратам һәм аның белән горурланам!

***Сәетгалиев Данияр***

*****

### Иң яхшы әти!

Җир йөзендә иң якын кешеләр әти-әниләрдер. Әтиләр гаиләдә һәр яктан терәк булып тора. Әтиләрнең канат астында үзеңне көчле һәм иркен хис итәсең.

Минем әтием шофер булып эшли, унҗиде ел юлда йөри. Ул эштән арып кайтса да, безнең белән уйнарга, безгә дәрес эшләргә булышырга көч һәм вакыт таба.

***4 нче б сыйныфы укучылары яза***



Алар әни белән унбер ел бергә яшиләр. Әтием әниемә дә яратып, матур сүзләр белән генә эндәшә. Минем әтием кебек әтиләр башка юк кебек.

Ул беркайчан авырмасын, гел шундый әйбәт, игътибарлы, ягымлы әти булып калсын. Мин аны бик яратам.

***Минеева Рүзилә***

*****

### Минем әти!

Минем әтием бик яхшы, уңган, кыю, шаян, тапкыр һәм кайгыртучан. Әтием һөнәре буенча экскаваторчы.



Ул үз эшен яратып башкара. Аның эше бик авыр һәм җаваплы. Әтиемне эш урынында да хөрмәт итәләр. Ул эштән кайтса өебезгә нурлар тарала. Апаем белән мин аны түземсезлек белән көтеп алабыз.

Әтием безгә олы терәк, зур таяныч һәм үрнәк. Мин әтиемне бик яратам, аның белән горурланам!

***Салахов Ранель***

## БҮГЕНГЕ ДӘРЕС ИРТӘГӘ ДӘ КИРӘК БУЛА

Без укытучыларны нәрсә өчен яратабыз? Бу сорауга күпчелек, мөгаен, гадел булган өчен, дип җавап бирер. Аннары инде кемдер – иҗади, кемдер – кызыклы дип өстәргә мөмкин. Сезнең игътибарга шундый укытучы белән булган әңгәмәне тәкъдим итәбез. Ландыш Фазыловна технология һәм рәсем дәресләрен укыта.

Без кергәндә, 5 нче в сыйныфында рәсем дәресе иде. Балалар үзләре ясаган рәсемләрен рекламалыйлар.

- Безнең дәресләр киләчәктә дә файдалы булырга тиеш, - ди Ландыш Фазыловна. – Кем белә, тормышта аларга, бәлки чыннан да, бизнес белән шөгыльләнергә, җитештергән товарларын рекламаларга туры килер.



***Рәсем ясау белән чынлап кызыксынган укучыга мәктәпне тәмамлагач дизайнер һөнәрен сайларга була. Бүген актуаль һөнәрме бу?***

- Әйе. Технология дәресендә без аш-су әзерләү, тегү, чигү, бәйләү, проект эшләре белән шөгыльләнәбез.

Укучыларның киләчәк тормышларында барысының да кирәге чыгачак.

***Дәрестә нинди билге куярга яратасыз?***

- Әлбәттә, бишле, дүртле, өчлене – сирәк куям. Эшләгән укучыга начар билге куясы килми.

***Өй эшләрен күп бирәсезме?***

- Юк. Укучыларның хәлен аңларга тырышам – аларның башка предметлардан да өй эшләре күп бит.

***Әңгәмәдәш***
***Замалова Зәринә***

# АЛДЫНГЫЛАР ХӘРӘКӘТЕ

**«АЛДЫНГЫЛАР ХӘРӘКӘТЕ»**
**Россия БАЛАЛАР һәм ЯШЬЛӘР ХӘРӘКӘТЕ**







Гимназиябездә «Алдынгылар хәрәкәте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең беренчел бүлеге рәисе һәм рәис урынбасары сайланды.

Совет рәисе вазифасына дүрт кандидатура: Биккинина Наилә Нәфис кызы, Сәгъдиева Адилә Илдар кызы, Латыпов Илназ Эдуард улы, Мәхмүдов Ислам Илдар улы заявка бирде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гимназиядә «Алдынгылар хәрәкәте» беренчел бүлеге советы рәисе итеп Адилә Сәгъдиева, ә рәисе - Илназ Латыйпов билгеләнде. Котлыйбыз, уңышлар телибез!!!

***

«Беренчеләр хәрәкәте»н «яңа пионерия» дип тә атыйлар. Максатлар һәм бурычлар бер үк, ягъни җәмгыять өчен файдалы белгечләр, тагын да гадирәк әйткәндә, яхшы кешеләр тәрбияләү.

**“Алдынгылар хәрәкәте”нең Социаль челтәрләренә кушылыгыз**

https://vk.com/myperviemuslumovo

https://будьвдвижении.рф/

@MYPERVIEGYMNASIUM

# ПСИХОЛОГ КИҢӘШЛӘРЕ



“Алдынгылар хәрәкәте”нең социаль челтәрләрендә мәктәп укучыларын беренче сентябрь алдыннан нәрсә борчуын ачыкладык. Сорауларга җавапны **психолог Наталья Королева** биргән.

***1. Мәктәптән соң ничек арымаска һәм башка әйберләргә көч табарга?***

Сентябрьдә безгә зур йөк өелә, шуңа күрә үзебез һәм халәтебезне кайгырту турында бөтенләй онытырга мөмкинбез. Һәр көнне үз көчеңне тулыландырыр өчен вакыт бүлеп куй: 15 минутлык җәяү йөрү, дустың белән сөйләшү, көндезге йокы, өй эшеннән ял иткән арада бераз күнегүләр ясау. Шулай итсәң, “янып чыкмаячаксың”.

***2. Ел башыннан ук ничек яхшы укый башларга һәм үзеңне формага китерергә?***

План төзү файдалы. Мәҗбүри эшләрне (мәктәпкә, өйгә, түгәрәкләргә бару) генә түгел, ә үз ялыңны да планлаштырырга киңәш итәм. Эш һәм тернәкләнү пропорциясе – яхшы форма нигезе.

***3. Игътибарны ничек тупларга?***

Төп ихтыяҗларың үтәлмәгәндә (йокламау, ашамау, ял итмәү) игътибарны туплау бик кыен булырга мөмкин. Бу очракта көн режимын җайга салырга һәм ашауэчүне көйләргә кирәк. Кечкенә генә үзгәрешләр дә ярдәм итә ала.

***4. Сыйныфташлар белән ничек дуслашырга?***

Гомумән алганда, дуслашу, татулашу – ике яклы процесс, монда кешеләрнең кызыксынуы һәм сөйләшергә әзер булуы кирәк. Беренче адымны син ясый аласың: аралаша башла. Килеп чыккан хәл турында фикер алыш. Бәхәсләшүнең сәбәбе нәрсәдә, дип сорау файдалы. Бу сөйләшүне зур компониядә түгел, ә конфликтта катнашучы кеше белән үткәрү яхшырак.

ТЫЛСЫМ+
Октябрь, 2023 нче ел
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Мингазова Камилә
**Корректорлар:** Мингазова Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Замалова Зәринә
**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ, Хаертдинов Ранис
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Тираж:** 100